РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 7 мае

Кукмара
шәһәре

№ 285

«Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләү хакында» Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 27 мартындагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләү турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 14 июнендәге карарын (Кукмара муниципаль район Советының 2013 елның 14 июнендәге 24 номерлы, 2013 елның 23 августындагы 34 номерлы, 2014 елның 23 маендагы 29 номерлы, 2015 елның 15 октябрендәге 13 номерлы, 2016 елның 29 мартындагы 35 номерлы, 2017 елның 14 июлендәге 105 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге 125 номерлы, 2018 елның 27 апрелендәге 156 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 184 номерлы, 2020 елның 13 мартындагы 275 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Карар) «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге №17-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына туры китерү максатларында Кукмара муниципаль район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимы гамәлдә булу шартларында Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән чикләү чараларын бозган өчен административ

җаваплылыкка тарту административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 20.6 статьясы буенча гамәлгә ашырыла, шуның нигезендә,

1.1 Карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.1 статьясы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактада үз исемен һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматларны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.8, 2.12-2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше, 2.16, 3.2-3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.16, 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (Кукмара муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль пассажирлар ташуга карата) статьялары белән» сүзләрен «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.1 статьясы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактада үз исемен һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматларны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.8, 2.12-2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше, 2.16, 2.17, 3.2-3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.16, 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (Кукмара муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль пассажирлар ташуга карата) статьялары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 Карарга кушымтада:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.1 статьясында (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактада үз исемен һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматларны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.8, 2.12-2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше, 2.16, 2.17, 3.2-3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.16, 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (Кукмара муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль пассажирлар ташуга карата) статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге».

б) таблицага түбәндәге эчтәлекле юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуын булдырмый калуга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү» ТР КоАПның 2.17 статьясы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Аппаратының (балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеге һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча) әйдәп баручы белгечләре |

2. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.17 статьясы, югары әзерлек режимын бетергәннән соң, яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуын булдырмауга һәм бетерүгә

юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәгәндә кулланылырга тиеш.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев